**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**АТНИНСКИЙ РАЙОННЫЙ СОВЕТ**

422750, село Большая Атня,
улица Ш. Марджани, дом 6

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘТНӘ РАЙОН СОВЕТЫ**

422750, Олы Әтнә авылы,
Ш. Мәрҗани урамы, 6 нчы йорт

Тел.: 8(84369)21004, факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

« 09 » июль 2026 ел № 39

**Татарстан Республикасы Әтнә район башкарма комитеты структурасына һәм Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфалары реестрына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында»гы 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, Муниципаль хезмәт турында 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе җитәкчесенең 03.06.2026 елгы Татарстан Республикасы Рәисе белән килештерелгән хезмәт язмасы нигезендә, идарә структурасын камилләштерү, Әтнә муниципаль районы җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру максатларында Татарстан Республикасы Әтнә район Советы карар чыгарды:

1. «Әтнә район башкарма комитетының эшләр идарәчесе» вазыйфасын кертү юлы белән Башкарма комитет структурасына үзгәрешләр кертергә һәм структураны 1 нче кушымта нигезендә яңа редакциядә расларга.

2. «Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләр реестрларын һәм Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының муниципаль хезмәткәрләр реестрын алып бару тәртибе турында»гы Әтнә район Советының 20.04.2021 ел, № 46 карары белән расланган Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфалары реестрына (Әтнә район Советының 28.06.2021 ел №55, 19.11.2021 №88, 29.06.2022 №128, 14.08.2023 №189, 25.04.2025 №270, 12.12.2025 №17 карарлары редакциясендә кергән үзгәрешләр белән) һәм 2 нче кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

3. Әтнә район Советының 2026 елның 10 апрелендәге 33 нче номерлы «Татарстан Республикасы Әтнә район башкарма комитеты структурасына һәм Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфалары реестрына үзгәрешләр кертү турында»гы карарын гамәлдән чыгарырга.

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге адрес буенча http://pravo.tatarstan.ru һәм Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында http://atnya.tatarstan.ru. адресы буенча бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Әтнә муниципаль районы башлыгы –
Әтнә район Советы рәисе Р.Ш.Хисамиев